**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№55** **25.03.2022ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбуклы авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 24 номерлы Зәй муниципаль районы Чыбуклы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт милкен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2007 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 1 июлендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Чыбуклы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбуклы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбуклы авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 декабрендәге 24 номерлы Зәй муниципаль районы Чыбуклы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль мөлкәтне аукционда сату

5.1. Әгәр сатып алучылар мондый мөлкәткә карата нинди дә булса шартларны үтәргә тиеш булмаса, муниципаль мөлкәт аукционда сатыла. Аны сатып алу хокукы сатулар барышында мондый мөлкәт өчен иң югары бәяне тәкъдим итәчәк сатып алучыга бирелә.

5.2. Аукцион катнашучылар составы буенча ачык булып тора.

5.3. Муниципаль мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан сату-алулар барышында ачык белдерелә.

Бер генә кеше катнашкан аукцион барып чыкмаган дип таныла.

5.4. Аукционда катнашу өчен гаризалар кабул итү аукцион үткәрү турында мәгълүмат хәбәрендә игълан ителгән датадан башлана, ул 25 көннән дә ким булмаган вакыт эчендә башкарыла. Аукционда катнашучыларны тану әлеге гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Аукционда катнашуны дәгъвалаучыларны катнашучы дип тану

күрсәтелгән гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

5.5. Аукцион үткәргәндә мәгълүмати хәбәрдә, әлеге нигезләмәнең 4.16 пунктында күрсәтелгән белешмәләрдән тыш, башлангыч бәяне күтәрүнең зурлыгы ("аукцион адымы") күрсәтелә.

5.6. Аукционда катнашу өчен алдан бирелә торган акча муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты күләмендә билгеләнә.

Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан бирелә торган акчаның керүен раслый торган документ булып әлеге счеттан өземтә тора.

5.7. Претендентка түбәндәге нигезләр буенча аукционда катнашырга рөхсәт ителми:

- тапшырылган документлар претендентның Россия Федерациясе законнары нигезендә сатып алучы булу хокукын расламый;

- мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән исемлек нигезендә барлык документлар да (аукционда муниципаль мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәрдән тыш) тапшырылмаган яисә күрсәтелгән документларны рәсмиләштерү Россия Федерациясе законнарына туры килми;

- гариза ,претендент тарафыннан мондый гамәлләрне башкаруга вәкаләт бирелмәгән зат тарафыннан тапшырылган;

- билгеләнгән вакытка мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан бирелә торган акчаның керүе расланмаган.

Аукционда катнаштырудан претендентка баш тарту нигезләре исемлеге төгәл булып тора.

5.8. Дәгъвачыны аукционда катнашучы дип таныганчы, ул теркәлгән гаризаны кире алырга хокуклы. Дәгъвачы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза кире алынган очракта, алдан бирелгән акча гаризаны кире алу турында хәбәрнамә кергән көннән соң биш көннән дә соңга калмыйча кире кайтарылырга тиеш. Гаризаны дәгъвачы гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң кире алган очракта, алдан бирелгән акча аукционда катнашучылар өчен билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла.

5.9. Бер зат бер генә гариза бирергә хокуклы.

5.10. Аукционда катнашучыны җиңүче итеп тану турында хәбәрнамә җиңүчегә аукционга йомгак ясау көнендә җибәрелә.

5.11. Аукцион җиңүчесе билгеләнгән вакытта мөлкәтне сату-алу шартнамәсен төзүдән читләшкәндә яисә баш тартканда алдан бирелгән акча аңа кире кайтарылмый һәм ул күрсәтелгән килешүне төзү хокукын югалта.

5.12. Аукционда катнашучыларга алдан бирелгән сумма, җиңүчедән тыш, аукционга йомгак ясаганнан соң 5 көн эчендә кире кайтарыла.

5.13. Аукцион җиңүчесе белән сату-алу килешүе аукционга йомгак ясаганнан соң 5 эш көне эчендә төзелә.

5.14 Аукцион уздыру нәтиҗәләре буенча билгеләнгән муниципаль мөлкәт бәясе аукцион нәтиҗәләреннән аерым дәгъвалана алмый.

5.15. Муниципаль мөлкәтне тапшыру һәм аңа милек хокукын рәсмиләштерү мөлкәткә тулысынча түләгәннән соң утыз көннән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе законнары һәм сату-алу шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

1.2. 6.5 пунктчада:

а) 3 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр сату-алуның берничә катнашучысы гавами тәкъдим аша беренче тәкъдимнең бәясен яисә «киметү адымнарының» берсендә барлыкка килгән тәкъдимнең бәясен раслаган очракта, аукционның барлык катнашучылары белән ачык тәкъдим аша мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр тапшыруның ачык формасын күздә тоткан әлеге нигезләмә нигезендә билгеләнгән аукцион үткәрү кагыйдәләре буенча аукцион үткәрелә. Мондый аукционда муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясе булып беренче тәкъдимнең бәясе яисә «киметү адымнарының» берсендә барлыкка килгән тәкъдимнең бәясе тора.»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр мондый аукционда катнашучылар муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясеннән артып киткән бәя турында тәкъдимнәр белдермәсә, аны сатып алу хокукы беренче булып муниципаль мөлкәтнең башлангыч бәясен раслаган аукционда катнашучыга бирелә.»;

1.3. 6.12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Гавами тәкъдим юлы белән сату-алу уздыру датасыннан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча җинүче белән сату-алу килешүе төзелә.»;

1.4. 7.2 пунктчаның өченче җөмләсендә «бирелә» сүзен «белдерелә» сүзенә алмаштырырга;

1.5. 9.7 пунктчаның беренче җөмләсендә «бастырып чыгару» сүзләрен «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **И.Н. Гадершин**